| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ<br>ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.10.2025 № 3

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге Башкарма комитетының 01.08.2025 ел,№2 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге бюджеты акчалары исәбеннән коммерциягә карамаган оешмаларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш)субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга туры китереп, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Алексеевск шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге Башкарма комитетының 01.08.2025 ел № 2 карары белән расланган коммерциягә карамаган оешмаларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш) Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге бюджеты акчалары исәбеннән субсидияләр бирү тәртибенә 1 нче кушымтаның 4.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. ТР Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге Башкарма комитеты:

4.2.1. әлеге Килешүнең шартларын үзгәртү турында карар кабул итә, шул исәптән әлеге Килешүнең 4.4.1 пункты нигезендә Алучы җибәргән мәгълүмат һәм тәкъдимнәр нигезендә.

4.2.2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының

Алексеевск шәһәр җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан субсидия бирү кагыйдәләрендә һәм шушы килешүдә каралган субсидия бирү тәртибен, максатларын һәм шартларын бозу, шул исәптән Алучы тарафыннан шушы Килешү нигезендә тапшырылган документларда төгәл булмаган белешмәләр күрсәтелү факты(о) билгеләнгән очракта, күрсәтелгән хокук бозуларны бетергәнче субсидия бирүне туктата,Алучыга хәбәр итеп, аны туктатып тору турында карар кабул ителгән көннән алып 7 эш көненнән дә соңга калмыйча;

4.2.3. Алучыдан шушы Килешүнең 4.1.6 пункты нигезендә Субсидия бирү кагыйдәләрендә һәм шушы Килешүдә билгеләнгән Субсидия бирү тәртибенең, максатларының һәм шартларының үтәлешен тикшереп тору өчен кирәкле документлар һәм мәгълүмат соратып ала.»

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Алексеевск шәһәр җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **И.К. Свистунов**